ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН! СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №144 (7317) | 30 ноябрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## *Мактаулы терлекчеләр*

«Россия» колхозы ит сату планын айдан-айга вакытыннан алда үтәп бара. Бу өлкәгә дуңгызчылык фермасы эшчеләре шактый зур өлеш кертә. Биредә быел узган ел белән чагыштырганда 700 башка артык үрчем алынды. Юлия Ивановна Имукова иң күп үрчем алучылардан исәпләнә. Зинаида Якимовна Белова, Мария Тимофеевна Кадяшева, Николай Васильевич Имуков мактаулылар исемлегеннән төшмиләр. Алар ноябрь аенда һәр баштан 400 әр грамм үсеш алдылар.

◇ Бер колхоз хәбәрләре

## Мәҗлесләр күңелле үтте

Муса Җәлил исемендәге колхозда соңгы көннәрдә эшлекле һәм күңелле вакыйгалар булып үтте. Бер көнне механизаторлар үз эшләре буенча үтелгән этапка йомгак ясадылар, икенче көнне терлекчеләр кышлату чорының үткән айлары турында фикер алыштылар. Мәҗлесләрнең һәркайсы мул итеп әзерләнгән табыннар артында колхоз һәм мәктәп ашханәләрендә үтте.

Биредә игенчелектә һәм терлекчелектә тырышып эшләүче алдынгыларның исемнәре аталды һәм аларның һәркайсына акчалата премия бирелде. Шулай ук лотерея уеннары да уйнатылды.

## Яңа профсоюз лидеры

Колхозда тагын бер эшлекле җыелыш булды. Ул профсоюзның отчет һәм сайлау җыелышы. Биредә профсоюз комитеты һәм ревизия комиссиясенең отчетлары тыңланды һәм соңыннан яңа профсоюз рәисе сайланды. Берничә ел буе колхозның профсоюз лидеры булып хезмәт итүче Гомәр ага Шакировның үзе теләп эштән китүе сәбәпле яңа рәис итеп Габдулла Нургалиевич Шәяхмәтов сайланды.

## Пенсионерлар алгы сафта

Пенсия яшемә җиттем, дип беркем дә өйдә утырырга җыенмый биредә. Хәер, хәзер авылда яшьләр хисапсыз кимегән чорда зур ышаныч шундыйларда бит. Әйтик, Һади Яруллин, Сәлихҗан Шәвәлиев, Габбас Нигъмәтуллин, Гариф Сафиуллин, Ислам Хәйруллин, Барый Шәяхмәтов, Ислам Мөхәммәтҗанов, Исмәгыйль Әхмәтов турында нәкъ шуларны әйтергә мөмкин. Алар сигезәү быел барлык терлекчелек биналарын да төзекләндереп, кышкы чорга әзерләделәр. Ул гына түгел, җәен печән чабуда да, салам җыюда да алар алгы сафта булды.

**Ф. ГАЛИМОВА.**





Төз, мәһабәт булып үсеп утырган агачларны егу беренче карашка кызганыч та кебек... Әмма табигать шуның белән безгә хезмәт итә дә: урман кыйммәтле һәм нык төзү материалы, ягулык һәм башка байлыкны бирә. Ә ул байлык Иван Аркадьевич Хурастеев кебек урман кисүчеләр кулыннан үтә. Һәр эшнең үз нечкәлекләре булган кебек, урман кисүнең дә сере, үзенчәлеге бар һәм Иван Аркадьевич 6 ел эшләү дәверендә аңа төшенергә өлгерде инде. Җитезлек, шул ук вакытта сабырлык, саклык, хезмәтенә намуслы караш аңа һәрчак әйбәт күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Хәер, мастер Иван Степанович Морозов җитәкчелегендәге комплекслы бригадада (ә ул нәкъ шунда эшли) андый уңганнар аз түгел. Әнә урман кисүче ярдәмчесе Петр Семенович Оренбуров та нәкъ шундыйлардан. Ул 1973 елдан бирле эшли Чулпан урман пунктында. Урман кисүче дә булды, тракторчы да, инде соңгы елларда агач егучы ярдәмчесе эшен башкара. Теләсә нинди һава шартларында да бу хезмәтнең һәркем өчен кирәкле эш икәнен аңлап, смена нормасын арттырып үтиләр урман эшчеләре.

Рәсемнәрдә: И. А. Хурастеев һәм П. С. Оренбуров.

Н. Азизов фотолары.

## Эшлекле сөйләшү

Күптән түгел «Путь к коммунизму» колхозында отчет профсоюз җыелышы элеккечә утырышлар залында рәсми төстә түгел, ә мастерскойда, механизаторларның турыдан-туры эш урыннарында эчкерсез сөйләшү рәвешендә барды.

Тармак эшчәннәренең авыл хуҗалыгы елы йомгаклары турында колхозның профсоюз комитеты рәисе Л. С. Ерепова сөйләде. Ул кыскача түбәндәгеләргә тукталды:

— Быел да ел игенчеләр өчен катлаулы булды. Аеруча язгы чәчү зур киеренкелек белән үтте. Чәчеләсе 3340 гектар мәйданның 445енә генә көздән арыш чәчелгән, 1200 гектар мәйдан җир туңга сөрелмичә калганга, бу эшне язын башкарырга туры килде һәм болар язгы культураларны чәчү сроклары сузылуга да сәбәпче булды. Ә инде игеннәр әйбәт кенә үсеп килгәндә, каты корылык килүе исә игенченең бөтен өметен җимерде. Халык әйтмешли, иген уңышы җиргә генә түгел, күккә дә бәйле әле.

Урып-җыю чорында да үстерелгән икмәкнең бөртеген дә әрәм-шәрәм итмичә кыска срокларда җыеп алу өчен кыр хезмәтчәннәре вакыт белән исәпләшмичә, көнне төнгә ялгап эшләделәр.

Лев Савицкий планда каралган 195 гектар урынына 381 гектар мәйданда иген суктырып, планны 195 процентка үтәде һәм хуҗалык комбайнчылары арасында 1 нче урынга чыкты.

Вячеслав Кончев 258 гектарда (132 процент), Валерий Ишмуллин 249 гектарда (121 процент) игеннәрне теземнәргә салды. Суктыруда шулай ук Вячеслав Кончев (3064 центнер), Андрей Львов (2553 центнер), Валерий Ишмуллин (2261 центнер) алдынгылыкны бирмәделәр.

Любовь Семеновна шулай ук җирләрне көзге чәчүгә әзерләүдә һәм туңга сөрүдә, уҗым чәчүдә, икенче урак — чөгендер алуда, терлекләргә кышка җитәрлек азык базасы туплауда катнашкан барлык механизаторларның да тырыш хезмәтләрен ассызыклады.

Мастерской мөдире А.И. Плотниковны, тракторчылар Н. И. Беловны, Е. И. Аркатовны, Ю. А. Прокопьевны, мастерскойда слесарь булып эшләүче В. П. Микушкинны, Ф.Т. Сосновны, балта остасы И. Л. Ереповны бирегә җыелган хезмәттәшләре 50 яшь тулу уңаеннан кайнар котладылар. Любовь Семеновна аларга колхоз идарәсе һәм профсоюз комитеты исеменнән Мактау кәгазе һәм истәлекле бүләкләр тапшырды.

Механизаторларның колхозның баш экономисты М. И. Лыковага да сораулары күп иде. Ул компенсация һәм 1 октябрьдән кертелгән хезмәт хакына өстәмә түләү тәртипләре белән таныштырды.

Механизаторларны борчыган күп мәсьәләләр күтәрелде бу сөйләшүдә. Запас частьләр булмау сәбәпле, ремонт белән шөгыльләнгән механизаторларның вакыты белән эшсез йөрү очраклары булуы, шулай ук мастерскойда эш шартларының канәгатьләнерлек булмавы һәм башкалар турында борчылып сөйләделәр бирәдәгеләр.

Хуҗалыкның баш механигы А. С. Фомин запас частьләр белән тәэмин итүнең һаман саен кыенлаша баруын, белгечләр тарафыннан бу юнәлештә күрелгән чараларны бәян итте, механизаторларга да бу сәбәптән тик торган очракта, кушылган башка эшкә алыну кирәклеген әйтте.

Җыелышта катнашучылар колхоз идарәсенә үзәк мастерскойны реконструкцияләүне 1992 елдан да калмый башлау зарурилыгы турында мөрәҗәгать белән чыгу турында карар кабул иттеләр.

Терлекчеләр белән шундый сөйләшү 15 нче һәм 20 нче ноябрьдә һәр бригадада аерым үтте. Тармак хезмәтчәннәре эшләре һәм үзләрен борчыган мәсьәләләр турында фикер алыштылар.

**Р. ШӘЙХУЛЛИНА.**

## Ишеттегезме әле...

Бүген республиканы сагалап торучы төп куркыныч — икътисадта, — дип белдерде Молдова Президенты Мирча Снегур. Хезмәттәшлек турында икътисади килешү төзелүгә карамастан, хаос сәйләп бетергесез төс алды, диде ул румын газетасы «Адевэрул» белән интервью вакытында. Президент фикере буенча, икенче реаль куркыныч — республиканы җимерергә маташу. Сепаратистларга гарантия бирелгән булса да, алар Молдованың федерализмы һәм конфедерализмы турында хыялланып, җимерү эшчәнлеген дәвам итәләр. Үзен диктаторлыкта һәм элекке коммунистик структураларны торгызуда гаепләргә маташуны Президент кире какты.

x x x

Кызыл Байраклы Кара Диңгез хәрби флотында якын көннәрдә тагын бер хәрби база барлыкка киләчәк. Ул Краснодар крае территориясендә урнашачак. Бу карарга Флотның төп базасы Севастопольнең суверен Украина территориясендә булуыннан килгәннәр.

x x x

Кыргызстан МВДсы самогон кайнату турында рөхсәт Указы хәзерли. Әлеге Указ спиртлы эчемлекләргә бәяләрнең кискен күтәрелүеннән соң килеп туган дефицитлык сәбәпле чыгарылачак.

x x x

Улан-Удэ халкы шәһәр үзәгендә Ленин бюсты өчен мех бүрек тегәргә карар кылганнар. Моны тегәргә теләк белдерүче исеме сер итеп саклана. Бөтендөнья юлбашчысы бюстының озынлыгы 2,5 метр. Гиннесс рекордлар китабына кандидат бюстка кабарда тиресеннән тегелгән бүрек кидерергә исәпли.

x x x

Түбән Кама «Нефтехим» берләшмәсенең беренче изопрен каучук заводында ясалма олифа чыгаручы тәҗрибә-промышленность цехы хезмәт күрсәтә башлаган иде.

Хәзер бу җайланма елына 6 мең тонна продукция бирә. Аңа чимал булып, элек беркайда да кулланылу тапмаган промышленность калдыклары хезмәт итә.

